| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге советы** |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>2020 ел, 24 ноябрь | **КАРАР**<br>№ 14 |

РЕШЕНИЕ КАРАР

Әлмәт авыл җирлеге Советының «Әлмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 июнендәге 9 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Әлмәт авыл җирлеге Советының «Әлмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 июнендәге 9 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге Советы Рәисе Д.Ә.Газизов